**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАГРАЖ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**К А Р А Р**

**№ 15** **15.01.2026 ел**

**«Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының 20.06.2023 елның 92 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Җирле салымнар суммасында бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының 20.06.2023 елның 92 номерлы Баграж авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) да, җирлекнең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегенә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **П.Н. Минеев**